**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БӘЗӘКӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

РЕШЕНИЕ КАРАР

2021 елның 23 мартыннан №5

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районының
«Бәзәкә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең
җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә
үзгәрешләр кертү буенча карар проекты турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 33 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясындагы 1 өлешенең 20 пункты, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Бәзәкә авыл җирлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Бәзәкә авыл җирлеге Советы,

КАРАР БИРӘ:

1. «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының «Бәзәкә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында» 2013 елның 27 маендагы12 номерлы Бәзәкә авыл җирлеге Советы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының «Бәзәкә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре» карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

«Шәһәр төзелеше регламентлары. Торак зоналары.» 35 статьяның «Шәһәр төзелеше зонасы картасында билгеләнгән территориаль зоналар төрләре» бүлегендә түбәндәге эчтәлекле 3 пункт өстәргә:

«3. Җир кишәрлекләренең иң чик күләмнәре:

«Шәхси торак төзелеше», «шәхси ярдәмче хуҗалыкалып бару өчен» рөхсәт ителгән файдалану рәвешендәге җир кишәрлекләрене ңминималь күләме – 1 000 кв.м.

«Шәхси торак төзелеше» рөхсәт ителгән файдалану рәвешендәге җир кишәрлекләренең максималь күләме - 2500 кв.м, «шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен» – 5000 кв.м.».

2. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Бәзәкә авыл җирлеге Советы Карары проектын карау буенча 2021 елның 23 апрелендә 16 сәгать 00 минутта түбәндәге адрес буенча ачык тыңлаулар үткәрергә: Татарстан Республикасы, Бәзәкә авыл җирлеге, Бәзәкә авылы,Үзәк ур., 46 йорт, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Бәзәкә авыл җирлеге башкарма комитетының административ бинасында.

3. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Бәзәкә авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проект буенча кергән тәкъдимнәрне исәпкә алу, гомумиләштерү һәм карау буенча эшче төркем төзергә.

4. Комиссиягә югарыда күрсәтелгән проектның демонстратив материаллары экспозициясен «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының «Бәзәкә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Бәзәкә авыл җирлеге Советы карары проекты белән таныштырырга,

кызыксынган затларның искәрмәләрен һәм тәкъдимнәрен түбәндәге адрес буенча кабул итәргә: Татарстан Республикасы, Бәзәкә авыл җирлеге, Бәзәкә авылы, Үзәк урамы, 46 йорт, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Бәзәкә авыл җирлеге башкарма комитетының административ бинасында;

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Бәзәкә авыл җирлеге башкарма комитеты бинасында, Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында https://mendeleevsk.tatarstan.ru/ «Бәзәкә авыл җирлеге» бүлегендә, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.

Бәзәкә авыл җирлеге башлыгы И.И. Кәшәфетдинов